Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

КАРАР № 9-1

Бәтке авылы 2017 елның 22 август

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советының
«Җир салымы турында»гы
2014 елның 14 октябрендәге
11 нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясындагы 4 өлеше, 31 бүлеге (икенче өлеш), «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 396-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 3 пункты, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә, " Россия Федерациясе Салым кодексының, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы карары:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 октябрендәге 11нче номерлы «Җир салымы турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 12 номерлы, 2015 елның 25 маендагы 12 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслаучы документлар салым түләүчеләр тарафыннан үз теләге белән салым органына тапшырыла».

2. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итәргә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН Р.06-1726/02 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000186
БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ